# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# КАРАР

14.03.2016 №14

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 13 мартында җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55, 56 статьясы нигезендә, участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләренең беренче нөсхәләре мәгълүматлары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе 2016 елның 13 мартында узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

"2016 елда Наласа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә карата, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән тыш, алар өчен түләүләр күләме 350 сум тәшкил иткән үзара салым акчасын җыярга һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге:
Наласа авыл җирлеге составына керүче юлларга вак таш җәю: Наласа авылы: (Яшьләр ур, Үзәк ур, Җиңү ур, М.Җәлил ур, М.Вахитов ур).
Урта Бирәзә авылы: (Татарстан ур, М.Вахитов ур).
2. Наласа авылында зиратның коймаларын урнаштыру һәм карап тоту
3. Урта Бирәзә авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта акчаны Наласа авыл жирлеге Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә" диган мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип танырга.

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 693 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны-658, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 94,95% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 641 (97,42%) кеше тавыш бирде, «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 17 кеше тавыш бирде, бу 2,58% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге территориясендә референдум узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип таныргa

2. "2016 елда Наласа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә карата, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән  тыш, алар өчен түләүләр күләме  350 сум тәшкил иткән үзара салым акчасын җыярга һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге:

Наласа авыл җирлеге составына керүче юлларга вак таш җәю: Наласа авылы: (Яшьләр ур, Үзәк ур, Җиңү ур, М.Җәлил ур, М.Вахитов ур).

Урта Бирәзә авылы: (Татарстан  ур, М.Вахитов ур).

2. Наласа авылында зиратның коймаларын урнаштыру һәм карап тоту

3. Урта Бирәзә авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта акчаны Наласа авыл җирлеге  Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип таныргa.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Җирле референдум нәтиҗәләрен Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге  башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева